Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Иске Кади авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены

# КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге составына керүче Тукай торак пунктында үзара салым кертү турында

24 октябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Тукай торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «2025 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Тукай торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- Тукай торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Тукай торак пунктында урам яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру).
- **янгынга каршы резервуарлар (янгын сулыклары), янгын пирслары төзү, ремонтлау** (Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкларга янгынга каршы керү юлларын торгызу);

2. Әлеге карарны Иске Кади торак пунктында, Совет урамы 6 нчы йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Иске Кади авыл җирлеге башлыгы Н.В.Мөктәсимов